**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОСТАВЫНА КЕРҮЧЕ КАЛМАШ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА**
**КАРАР**

24 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган граждannar җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Калмаш авылында урам утларын ремонтлау;
- Калмаш авылы юлларын ремонтлау.
- Калмаш авылы ограждение водозаборной башни.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **1199** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **599** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **591** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **8** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2023 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йоз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йоз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Калмаш авылында урам утларын ремонтлау;

- Калмаш авылы юлларын ремонтлау.

- Калмаш авылы ограждение водозаборной башни.

3. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен http://tukay.tatarstan.ru Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмаш авыл җирлеге Башлыгы депутат — Салихова Г.И